Закир Әкбәров

# Галәмәт тормыш





Закир Әкбәров

Центральной библиотеке с наилучшими пожеланиями от автора З. Акбаров 24 08 2017г

# Галәмәт тормыш

*Мәсәлләр*

Күмертау, 2017 ел

ББК – 84(2Рос)
А – 38

Әхбәров З. Н. (Закир Әхбәров)
Галәмәт тормыш. Мәсәлләр. Күчертү: ШЭ Икрам Әхмәдов басмаханәсе, 2017. – 96 бит.

Бу җыентыкка әдипнең соңгы елларда язган мәсәлләре тупланды.
Аларда ул җәмгыятьтәге кире күренешләрне, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне ачып сала, җитешсезлекләрдән көлә.

© Закир Әхбәров 2017

# КЕРЕШ СҮЗ

## УЙНАП ТА, УЙЛАП ТА...

*Мәсәл – безнең эрага чаклы ук барлыкка килгән әдәби жанр. Борынгылардан бу жанрга нигез салучы Эзопны беләбез. Урта гасырларда француз шагыйре Лафонтен үзенең үлемсез әсәрләре белән танылу тапкан. Унтугызынчы йөздә яшәгән рус әдибе Иван Андреевич Крыловның мәсәлләрен укып, кайсы берләрен ятлап үстек. Классикларыбыз Габдулла Тукай белән Мәҗит Гафуриның мәсәлләре дә күңелләребез почмагында үз урыннарын алган. Совет чоры шагыйре Сергей Михалков иҗатының байтак өлешен мәсәлләр алып тора. Замандаш сатирикларыбыз Марсель Сәлим белән Рәдиф Тимершинның мәсәлләре озак еллар буе «Һәнәк» журналында, башка басмаларда көн күрә, байтак укучыларны яшәешебез, җәмгыяттәге кире күренешләр, үз ара*

мөнәсәбәтләребез, холкыбыздагы житешсезлекләр турында уйланырга мәжбүр итә килде.

Әйе, мәсәл – сатирик жанр. Тулыландырыбрак әйтсәк, кагыйдә бозарак, шигъри формада язылган, киекләр, кошлар образлары аша, кайчагында жансыз предметларны «жанландырып», сатира белән сугарылган кыска хикәят.

Мин – прозаик, сатирик һәм юмористик хикәяләрем, повестьларымны туплап, берничә китап чыгардым. Тормышыбыз, чынлап та, галәмәт тормыш. Халыкка бик аңлашылып житмәгән реформалар көн дә яңалыклар тудырып тора. Болганчыклыктан файдаланып, кайсы бер түрәләребез урлый, ришвәт ала, чит илләргә чыгып китеп, типтереп яшәп ята. Гади халыкның бик күбе түбән эш хакына, йә булмаса пенсиягә көн күрергә мәжбүр. Бихисап предприятиеләр, күмәк хужалыклар таркалды, кешеләр эшсез, яшәү чыганагысыз



торып калды. Шуларга жәмгыятебездә «котырып чәчкә аткан» эчкечелекне, наркоманияны да өстәсәк... Гомумән, сатирикка язар нәрсәләр күп, күп кенә түгел баштан ашкан. Байтак темалар хикәя, повесть калыпларына сыеп та бетми. «Хатка язып сүзем бетми, бик күп сүзләрем кала» дип әйтелә бит бер жырыбызда. Менә шушы «бик күп сүзләр калу» галәмәте мәсәл жанрына мөрәжәгать иттергәндер инде бу юлларның авторын.

Тәү башлап үзем өчен генә. Аннары газит-журналларга да биргәли башладым. Кайсы берләре турында мактау сүзләре дә ишеткаладем. Хәзер инде «Агизел»дә, «Һәнәк»тә, «Чаян»да, «Кызыл таң»да, «Юшатыр»да, «Көнгәк»тә дөнья күргәннәре дә байтак булып китте. Шуңа күрә уйнап та, уйлап та дигәндәй язылган мәсәлләремнең бер өлешен, жыентык итеп чыгарып, киңрәк катлам укучыларга тәкъдим итәргә булдым.

«Җитешсезлек» дип әйтәсем килми, әсәрләремнең үзенчәлекләре дә юк түгел. Мәсәл ике өлештән торырга тиеш: хикәят үзе һәм аның «моралы» дип аталган өлеше, ягъни әйтелгәннәрдән нәтиҗә чыгарып кую. Минем мәсәлләремнең күбесе нәтиҗә чыгаруны таләп итми. Димәк, жанр канунынан читләшкәнмен. Традицион мәсәлләрнең геройлары – хайваннар һәм кошлар. Мин мәсәлләремдә җансыз предметларны да «җанландырдым». Жанр кануннарыннан читләшүемне укучым дөрес кабул итәр дип өметләнәм.

*Автор.*



Ишәк баш булган далада,
Атның токымы корый.

# ГАЛӘМӘТ ТОРМЫШ

Ни гыйлләләр, ни зәхмәтләр,
Урманга каза килде:
Күз ачып йомган арада
Урманның халкы бөлде.

Аю ирек игълан итте,
Яшәсе, демократия!
Кем урлап өлгерә байлыкны,
Ул байлык шуңа тия.

Байлык Бурсыкка эләкте –
Ни гыйлләләр, ни зәхмәт.
Бурсык – игелексез җәнлек,
Көтмә Бурсыктан шәфкать.

Комсызлыктан шардай булды
Бурсыкның кысык күзе.
Дуңгыздай булып симерде,
Көн-төн мыркылдый үзе.

Урман кырып вилла салды,
Акланны газон итте.
Кызармагач кызармый бит
Оятыннан Бурсык бите!..

Бассейн итте күлне ул
Су кергәләп торырга,



Фахишәләр җыеп төнен
Пәри туе корырга.

Чишмәдән фонтан ясады,
Дөньясын торсын ямьләп.
Төмләп виски эчә Бурсык,
Ылдык ашый тәмләп.

Урманны камап алды ул
Бик биек койма белән.
Капкада сак, керсәң түлән,
Чыгасың килсә, түлә.

Җәнлекләргә бетте тормыш,
Калдылар авыр хәлдә.
Инде тезеп социализм
Бетәбез дигән мәлдә.

Куян үрчеми кишерсез,
Бүре ачка каклана,
Хәер эсти мескен Тилке,
Токчай тотып аклана.

Селәүсен меңәлми агачка,
Төп башында утыра.
Керпе чүплектә чокына,
Үзе нидер укына.

Күлдән читтә иза чигә
Шешкә белән бер Кондыз.

Су булмагач, калды алар
Ашар азыксыз, тунсыз.

Аю көн күрә Бурсыкта
Йомышчы булып малай.
Үзе күкрәк суга һаман:
– Шәп тормыш кордык калай!

Җәнлекләр ачулы, әмма
Бурсыкка алмый тия,
Менә шундый була икән
Аюча демократия...





# КАРГАЛАР

Фиркә оештырды карга халкы,
Монда без иң бердәм халык дип,
Кош иленә килсә бәла әгәр,
Аны өстебезгә алыйк дип,
Ватанга без тугры калыйк дип.

Менә җәй дә үтте. Кошлар өчен
Килде авыр көннәр – кыш озын.
Җылы якта, диңгез буйларында,
Ял итәр чак байлар – шәп сезон!

Бердән бер көн фиркә әгъзалары,
Яуга купкан кебек куптылар.
«Карр» да «карр» дип, кара болыт булып,
Кыйблаларга карап очтылар.

Кемнәр калды, дисез, Кош илендә?
Авырлыкны кемнәр күтәрә?
Илгә тугры кошлар – фиркасезләр.
Кырыс кышны илдә үткәрә.

# САЕСКАН – ДЕПУТАТ

Саесканга ниндер булды,
Бөтенләй китте азып.
Уңган Чүкә туганыдай,
Җирдән эзләми азык.

Кайда басканын да белми,
Йә сикерә, йә ыргый.
Анда барып хәбәр сөйли,
Монда килеп шыкырдый.

Хәбәре дә хәбәр түгел,
Вәгъдә дә вәгъдә генә.
Имеш, ул депутат булса,
Бар кошлар файда күрә.

– Миңа тавыш бирәсез, – ди, –
Әй кошларым, белегез:
Тәнәрегез тыныч булыр,
Якты булыр көнегез!..

Җәйләрегез эссе булыр,
Йомшак булыр кышыгыз.
Тормыш шулай яхшыруга
Алынмасын һушыгыз.

Чыпчыкларның төп азыгы
Тары гына булачак.



Каргалар үз ояларын
Тик бамбуктан корачак.

Туктаусыз чебеш чыгарган
Инкубатор ясатам.
Тилгәннәргә чебешләрне
Җәлләмичә ашатам.

Йомырка салуыннан мин
Күкене азат итәм.
Миңа гомерләр теләсен
Көн саен кичен, иртән.

Сәхнә булмас Сандугачка
Юк-бар әрәмә талы.
Аңа атап төзеп бирәм
Аерым концерт залы.

Гиннес китабына кертәм
Карлыгачның рекордын.
Уктай атылып очканын
Мин үзем карап тордым!..

...Сайлаудан митинг ясап,
Әйләндерми болага,
Кошлар дөррәү сайладылар
Саесканны Думага.

Кышлар үтә, килә язлар,
Яз артыннан җәй җитә.

Сайлаучылар вәгъдәләрен
Үтәлүләрен көтә.

Бу хикәяттән нәтиҗә
Чыгарып торасы юк.
Сәясәтчеләрнең файдалы
Бер эш тә кырасы юк.







# ЙОЗАК

Элделәр келәткә Йозак,
Бер потлысын, иң зурын.
Кисәттеләр:
– Постта нык тор!
Бик җаваплы бу урын.

Синең кулга тапшырабыз
Зур байлык. Уяу сакла!
Бурларны якын җибәрмә,
Ышанычларны акла.

Керфек тә какмый көн-төн
Капканы саклый Йозак.
Бурлар читтән урап үтә,
Тукталып тормый озак.

Йозакка сәлам бирәләр,
Көлеп ары китәләр.
...Тактасы черек келәтне
Арт ягыннан сүтәләр.

Озакка бармады бу эш,
Келәт тә юк, байлык та.
«Зур» дип бәһаланган байлык
Булмады бер айлык та.

Ике багана, бер капка
Калды кырда сереп.
Корсагын киереп Йозак
Постта тора иреп.

# КӘҖӘ БЕЛӘН САРЫК

Кемне кайда куярга дип,
Өстә бик нык уйлыйлар.
Кәбестә бакчасын сакларга
Кәҗәне бит куймыйлар.

Куйдылар Сарык тәкәсен,
Хәзер җаннары тыныч.
Зур кәбестә бакчасына
Һич янамый куркыныч.

Тик Сарыкка Кәҗә килде:
– Мин сиңа гашыйк, – диеп, –
Кәбестәң бик уңган икән,
Бергәләп ашыйк, – диеп.

Кунакның чибәрлегенә
Һушы китеп, таң калып,
Икеләнми, кәҗә кызын
Якыны итте Сарык.

Оҗмах мәхлуклары кебек,
Белми шикләнү, хафа,
Кәҗә, Сарык җәй буена
Кордылар кәеф-сафа.

Түрә килде тикшерергә...
Юк кәбестә, юк бакча.



Юк ихата яңартырга
Тәгаенләнгән акча.

Мескен Түрә җәза тапмый,
Баш ката, булып гарык.
Ватмас иде, ул үзе дә,
Чыгышы белән сарык.



## ЧИКЕРТКӘ БЕЛӘН КЫРМЫСКА

Көзнең суыгында түгел,
Эссе җәй уртасында
Кырмыска тора, баш иеп,
Чикерткә тупсасында.

Балконда тәмәке тарта
Чикерткә – Озын Сыйрак:
– Нишләп йөрисең йолкыш? – ди, –
Тизрәк моннан олак!..

Кырмыска кашый җилкәсен,
Тамагын кыра-кыра,
Күзен алмый Чикерткәдән,
Һаман ялварып тора:

– Әй Чикерткә! Хәлемә кер.
Иген уңды быел бик.
Ягулык, запчастька акча юк.
Биреп торчы кредит.

Чикерткә: – Баемассың, – ди, –
Болай теләнеп йөреп.
Ныклабрак уйлар идең,
Шөгыль сайлардан элек.

Рольләр нигә алышынган?!
Җавап – бер. Җавап – анык.
Фермерлык итә Кырмыска.
Чикерткә тота банк...



## БӘХӘС

Өңдә булды микән бу эш, әллә инде төштәме?
Йә булмаса сер ачылды берәр сихри кичтәме?..

Очрашты суык чоланда, булып серсез, төссез,
Дүрт элгечтә эссез калган дүрт иске баш киеме.

Фуражка һәм Шәпке бүрек, каракульдән Папаха,
Бейсболка бу өчәүгә тиңләшергә маташа.

Папаха һәм Бейсболка, Фуражка, Шәпке бүрек
Арасында бәхәс купты: кемнең хуҗасы бөек?

Бейсболка күкрәк суга: – Минем хуҗам – дзюдоист!
Кулга чумса, ул – подводник, танк эчендә – танкист!

Үзе тәбәнәк булса да, рейтингысы югары.
Андый хуҗа илебездә булганы да юк әле.

Шәпке бүрек көлде генә: – Бик мактанма син алай.
Синең хуҗаң минекендә булды йомышчы малай.

Сәркүш булса да, миңеке күпме эш кырды
бөек.
Ил таркатып, күкрәк сукты: «Мин Бушның
дусты!» – диеп.

Чират җитте Папахага: – Хуҗам чөчте
кукуруз!
Буржуйларга карата ул булды һәрчак бик
кырыс.

Зур җыенда, туфли салып, өстәлен төйде
кат-кат.
Залдагыларга янады: «Покажу кузькину мать!»

Бик күпләрнең әле һаман кило эзләп табасы:
Кайларда кем күрә икән шул Кузьканың анасы?

Тамагын кырды Фуражка, бүлеп Папаха сүзен.
Мыскыллап карады аңа, күздән кичерде үзен.

Дәшмәде. Чөнки бәхәс тә туктап калган иде.
Шул тамак кыру өчүне шөбһәгә салганг иде.

...Үтә еллар. Үзә дәвер. Санап бара
календарь.
Бәхәсләшүләр туктамый сәясәтчеләр, галимнәр.

Баш киемнәре бәхәсе – бер мәзәк ул кечкенә.
Сөйләсәң – торганы ялган. Сөйләмәсәң –
төш кенә...



## АЮ һӘМ БҮРЕЛӘР

Аюның әрсезлегеннән
Кырылып күңелләре,
Беркөн саммитка җыелды
Тирә-як бүреләре.

Олы Бүре нотык тотты:
– Аю чиктән чыкты, – ди, –
Болай да зур үз җирен
Күрше җирен кушты, – ди. –

Куяннар илендә сугыш
Кишер басуы өчен.
Йә җиңә үр куяннары,
Йә аклар чыга өстен.

Ак куяннарны үрләргә
Каршы котырта Аю.
Үз: мескен куяннарның
Исәпләрен баю.

Аюдай мәкерле түгел,
Без намуслы киекбез.
Куян туганнарыбызны
Без якларга тиешбез.

Солых балын үзе ашый,
Безгә чыгармый өлеш.

Аюга ләззәт – бал ялау,
Бал кортларына – үлеш.

Сарык фермабызга да ул
Барып килгәли, диләр.
Браконьерлык кылып, күлдә
Балык сөзгәли, диләр.

Бу кырын эшләре Аюның
Җанварыбызга тия.
Аңа каршы кирәк игълан
Итәргә санкция.

Солык балын ашамасын,
Җыймасын җиләк-җимеш,
Балык тотуыннан да ул
Туктап калырга тиеш.

Яшисен без, бүреләрсен,
Рәхәте белән генә,
Ашаса да, тик ашасын
Болында үлән генә...

Бу тәкъдимне бар бүреләр
Бертавыштан хуплады:
– Санкциябез бик шәп! – дип,
Бер-берсен котлады.

Саммит әгъзалары риза
Булып кайтып киттеләр.



Санкциягә дучарның
Ни әйтерен көттеләр.

Аю ни әйткән? Балны ул
Ашаган, ашыячак.
Аю канунары белән
Яшәгән, яшәячәк...



# ӨЧ ЭТ

Беркөн шулай тын тыкрыкта гауга купты,
Эт белән эт арасында ызгыш чыкты.
Эзли торгач, Ак эт сөяк тапкан иде,
Ләззәтләнеп кимерергә яткан иде.

Бәхетләнеп бер Кара эт килде күреп,
Өрә-өрә килеп җитте ул йөгереп.
– Сөяк яткан бу тыкрык – минем төяк,
Шулай булгач, сөяге дә – минем сөяк.

Сөякне бит кимерергә мин тиеш, – ди,
Синә тотемәскә тиеш бу әйбер, – ди.

Агы әйтә:
– Сөякне бит мин таптым, ди,
Аны тәмләп кимерергә мин хаклы, – ди –
Олак моннан бугазыңнан алмас борын,
Мир алдында мәсхәрәгә калмас борын.

Бу әйтешү, бәлки, зурга китмәс иде,
Сүздән үтеп, әзгәләшкә җитмәс иде,
Кысылмаса килеп бәхәскә Ала эт.
(Ул малгуньнең котмә һич кайчан игелек).

Ак этне ул пышылдады:
– Ниятең – ак!
Чәмләндерде Кара этне:
– Дәгъваң бит хак!



Сүзеңне син тартынмыйча үтәшыр алга,
Җиңеп торма дошманыңны, түләшыр канга!

Купты сугыш, бөрелеште тешләр тешкә,
Чакматаштай чакыштылар тешләр тешкә.
Авызлардан, борыннардан каннар акты.
...Ахыр этләр, хәлдән таеп, барып ятты.

Шыңшый-шыңшый яраларын ялаштылар,
Аптырашып, бер-берсенә караштылар.

Арадаш эт әллә кайда киткән иде,
Сөяктән дә инде җилләр искән иде.



# ИШӘК

Көлим дисәң, көл, укучым. Кайгырыйм
дисәң, кайгыр.
Өергә теләми куярга баш итеп юньле айгыр.

Куйшылар китерен Ишәкне баш итеп
елкыларга,
Булмаса да риза күнү бу хәтле мыскыллауга.

Дипмәдесләр. Имеш, Ишәк өстенә Зур
Хуҗаның
Булып чыкты әллә дусты, әллә якын туганы.

Нидән башлады, дисезме? Озак уйлап
тормады,
Яшь түрә Нәсел айгырын әттән куып
чыгарды.

Боерды атларга иске гадәтләрен ташларга.
Ишәк кануннары белән яңа тормыш
башларга.

Кылганлы тауда тибенү – бу шигаль азык, –
диде.
Шайтан таягы кимерү – вот сезгә азык, –
диде.



«И-һа-һа!» дип хәбәрләнүнең бигрәк тупас, –
диде;
«И-а!», «И-а!» дип дәшергә – вот сезгә указ, –
диде.

Айлар узды, узды еллар. Гомерләр уза торды.
Картайган атларга алмашка качырлар туа
торды.

Үсмәде хәзер өердә яу чабар дап-дап атлар.
Бәйгеләрдә ярсып җилләр, ал бирмәс
аргамаклар.

...Бу тарих, тешенмәгездәр, нәтиҗә ясау
сорый:
Ишәк баш булган далада атның токымы
корый.



## ГАДЕЛ БҮРЕ

Ата Бүре – гадел җырткыч, һәркем белә,
Гаделлек дип каты тора, үлә үлә.
Бугазлаган һәр сарыкны өерен
Бик чамалап, бик нык уйлап, тигез бүлә.

– Яшь Бүребез – миңа алмаш өер башы,
Бар урманның горурлыгы, йөзек кашы.
Акыллы да булып үсәр – мин ышанам...
Сарык башы – Яшь Бүренең ашар ашы.

Изге булды, – ди – әнисе һәрчак үен,
Өеребезнең ямь бит, – ди, – сының, буең.
Ана Бүре исән чакта – исән өер.
Рәхәтләнеп кимерерсең, сиңа – муен.

Ә сез минем дүрт күчегем, күчеккәйләр.
Кышлар үтәр, килеп җитәр ямьле җәйләр.
Таман булыр һәр берегезгә берәр тояк.
Үсәрсез сез җитез булып, йөгрекәйләр.

Сездән арткан калдык-постык шушы килеш
Ризыгыма язса, димен, булыр дөрес.
Миңа олы ни кирәксен, мин инде карт.
Мин ризамын, гәүдә булса минем өлеш.

...Кырыс кыш та үтеп китте, үтте зарык.
Күрше ферманың казасы – җиде сарык.



Каршы алды яңа өер исән-имин,
Баш Бүре юк, калганнары бик тә арык.

Өер менә шундый хәлдә җәйгә керде,
Ата Бүре Аюханга отчет бирде:
– Уртачалап санаганда һәр бүрегә
Кышын тогал берәр түшкә сарык тиде.

Мораль дип ни... язмабызның морале юк,
Бу дөньяда берәүләр ач, берәүләр тук.
Уртачалап исәпләсәң, бар да тигез.
Бар да әйбәт, рәнҗетелгән бәндәләр юк.



## БӨРКЕТҺӘМ ЧЫПЧЫК

Сандугачны күтәргәннәр,
Юбилейын үткәргәннәр.
Хәтта Бөркет үзе килгән,
Указ язып исем биргән.
– Арттыру юк, как есть, – дигән, –
Заслуженный артист! – дигән.

Чыпчыкның да эше җиткән,
Бөркеткә ул үзе киткән.
Патша яшәгән кыяга
Менә-менә хәле беткән.
– Мин дә җырчы бераз, – дигән, –
Миңа да яз указ, – дигән.

«Народный»-ны бик күпсенсәң,
«Заслуженный» булырлык мин.
Тырышыбрак җырласам,
Сандугачны узарлык мин.
Мактый мине Карга үзе,
Песнәк язды бәһа сүзе...

Бөркет әйткән:
– Кайт йортыңа,
Котыртсалар да, котырма.
Җырчымын дип черкелдәп,
Кыяга менеп утырма.
Җирдә чокын, ашарга тап...
...Ни әйтсәң, дөрес җавап!



...Сәхнә инде чуарланды,
Чыпчыклар ишәйде харап.
Тик Бөркет юк әйтәлерлек
Дөреслекне күзгә карап.



## ТУКРАН ТӘҮБӘСЕ

Юктан бар байлар күбәйде, гаҗәпләнмибез
бүген.
Тукранбикә шундый бичә – бусы да гаҗәп
түгел.

Гаҗәбе шул: надан улын күрше вузга
бирмәде.
Укысын, тукран булсын дип чит бер илгә
җибәрде.

Бакалавр булып кайтты, укып анда җиде ел.
Кем булырга укыганын атап әйтүе кыен.

Профессоры булган диләр Ара атлы попугай.
Кеше үчекләү буенча бик тә зур белгеч, бугай.

Бөҗәк эзләми Тукран, «тук» та «тук» агач
чокып,
Утыра, узган бер кошка «Попка дуррак» дип
тылкып.

Өйләнмәде. Алмады ул әнисен сөендерә».
Әнисе ашата хәстәрләп, әнисе киендерә.

Тукранбикә тәүбә итте башка бала тапмаска.
Тапкан хәлдә дә укырга чит илгә озатмаска.



## ЧУРТАН БЕЛӘН ТАШБАШ

Бервакыт Чуртанның тамагы туйган ди.
Балыклар өерен йөрми ди туздырып.
Ята ди сай җирдә, хисләргә бирелеп,
Ята ди кояшка аркасын кыздырып.

Бер Ташбаш булган ди бу хәлнең шаһиты.
Шул күлнең каршы як читенә барышлый.
Курккан ди. Курка да нигәдер туктаган,
Кызыгу хисенә, күрәсең, карышмый.

Күргән ди Чуртанның чынлап та туклыгын,
Күңелендә берничә начар уй юклыгын.
Батырлык өстәгән Ташбашка Чуртанның
Күзәтеп ятуы маймычлар уйнаклыгын.

Гомерендә тәү тапкыр Чуртанга дәшкән ди
(Көнләшсен, әнисе, күлдәге бар халык):
– Шат сине күрүгә, хөрмәтле падишаһ,
Балыклар башлыгы, абруйлы ханбалык!

Кырыссың, бәхәс юк, әмма да гаделсең,
Талымсыз Шамбыдай түгелсең, галәтсез.
Күзлисең син безне, сыныйсың һәрьяклап,
Йотмыйсың беркемне берничә сәбәпсез.

Арада сөмсезләр әлегә җитәрлек:
Алабуга, кәрәкә, вак-төяк чабагы...

Йотып син аларны бик дөрес эшлисең.
Күлебез талара, тук була тамагың.

Ялагай балыклар бу күлгә җитәрлек,
Мактаулар хәҗкән Чуртанга элек тә.
Шулай да Ташбашның сәламен алган ул.
Чынлапмы? Бәлки, дәшкәндер Ташбашка
килеп тә.

Әйткән ди:
– Мин бит карт, колакка катырак.
Читтәрәк торып син әллә ни сөйләдең?
Янымга килсәнә, тагы бер кабатла.
Күңелгә ятышлы, алрмсы, сүзләрең.

Ташбаш ни килгән ди, якадан башлаган.
Чәйнәп тә чәйнәми ди бер үк шул сагышын.
Ә Чуртан ялгышмы, уйнапмы, уйлапмы
Зур итеп ачкан да япкан ди авызын.

Сүз тәмам... Ташбаш юк...Йә инде
нишлибез?
Юк үзе, юк үзе, юк монда, юк анда.
Ташбашлар хәленә белмисең керә дип.
Гаепләү ташлыйкмы ваемсыз Чуртанга?..

Нәтиҗә бик гади: комагай Чуртанның
Туйса да тамагы, күзләре туймыйдыр.
Ташбашлар! Белегез, арырак йөрегез!
Чуртанның эшләсе һичкайчан булмыйдыр.



# АЮ – ФӘН ДОКТОРЫ

Берчак шулай эрсез Төлке
Аю янына килде.
Хәл-әхвал сорашкач, аңа
Бер сәер сорау бирде.

– Аю абзый, гамьсез яшәү
Туйдырмадымы сине?
Синең кебек олпат ирләр
Галим булыр чор килде.

Дусларым бар баш урманда,
Бик гыйлемле киекләр.
Теләсәң сиңа да докторлык
Ясап бирер кебекләр.

– Соң бит... – дип жәелә калды,
Уфтанды Аю аннан. –
Минем бит барлык һөнәрем –
Азык табу урманнан.

Хәреф танымаган киек
Галим була аламы?
Галимлелеге белән
Ашар азык табамы?

Төлке әйтте: Нигә белем,
Докторлыгың булганда?
Син бит болай да дәһисың
Үзебезнең урманда!

Бүрегә ясашып бирдем,
Ул хәзер фән докторы.
Сарык югала, тик Бүре
Судан чыга коп-коры.

Чөнки сарык үрчетүдә
Иң зур белгеч ул бүген.
Тамагы тук, өсте бөтен,
Муллыкта күрә көнен.

Узган айда Куян килде.
– Мине дә доктор ит, – дип, –
Күзләрем кылый булса да,
Акылым тулы бик, – дип.

Доктор аңа күп булыр дип,
Кандидатлык ясадык.
Дәрәҗә юганда ялгышып
Үзен тотып ашадык.

– Ярар, Төлке, фән илендә
Ни биреп узарга соң?
Доктор наук булу өчен
Күпмедән чыгарга соң?

– Бер мичкә бал, тушкә үгез,
Авыз итәрлек балык.
Боларын өстәгеләргә,
Миңа – бер оя тавык.



Бал да, ит тә юнәтте ул.
Тапты бер оя тавык.
Аю хәзер фән докторы,
Доктор берложных наук.

Төртсәң күз шул, сөйләсәң сүз,
Сүзе дә көлке менә.
Аю лекция укый вузның
Пошилар төркеменә.

Имтиханда сорау биреп
Талипларын йолкта.
Тояк ялап, кышны өндә
Уздырырга өйрәтә.



# БАКА ЯЗМЫШЫ

Балыкларга башлык булды күлдә Бака.
Бу кызыктан күл халкының сыны кита.

– Шул да булган икән, имеш, солтан, – диләр.
Бу эшкә соң ник кызыкмый Чуртан, – диләр.

Чуртан, хәйләкәр елмаеп, җилкә кашый.
Ул бит бакадан җирәнә, балык ашый.

Баксаң, балык ашавыннан бик нык туйган.
Күл Бакасын түрә итеп үзе куйган.

Уылдыктан да шәп азык юк – татлы җимеш!
Уылдык белән тукланса, файда, имеш.

Хәзер Бака көн-төн йөри балык савып.
Ташый Чуртанга уылдык савыт-савыт.

Ә Чуртан һәр ташыганны йотып куя.
Аптырарлык: шул чаклы җим кайда сыя?!.

Уылдыксыз үрчемиләр һич тә балык.
Калмады күлдә Чуртанга беркем азык.

Бик ачыккач, җирәнүдән йомып күзен,
Уйлап тормый, йотып куйды колының үзен.



# КӨРӘШҮ

Аю патша җыйды аю туганнарын,
Төбәкләрдә түрә булып торганнарын.
Киекләрнең вәкилләре рәвешендә
Бүре, Төлке катнаштылар кор эшендә.
Күрделәр: бик тә борчулы патша йөзе,
Орандай яңгырады һәр әйткән сүзе:
"Әй, туганнар! Илнең рәте китеп бара.
Бабайлардан калган байлык бетеп бара.
Бурлык атлы яман гадәт җанга тия.
Чәчкә ата ришвәтчелек, коррупция.
Берәү белми, кая оча умарталар,
Кемнәр урлый, кемнәр аны урлаталар?!.
Фермаларда сарык саны һаман кими.
Кем буталды соң аларны – беркем белми.
Тавыклар да берәм-сәрәм калды..."
Менә шушы сүзне инде Төлке алды:
"Аю абзый! Уйлавымча алны-артны,
Көрәшик без бурлык белән беспощадно!
Соңгы тамчыга калганчы көрәшик без.
Угрылыкның булмавына ирешик без!"
Бүре хуплады Төлкенең бу сүзләрен:
"Кызармый бит һаман бурларның йөзләре!
Барса болай эш, я сарыксыз калабыз,
Я бурларга штрафлар салабыз..."
Аюлар бу сүзләр белән килештеләр:
"Вәкилләр тәкъдиме дөрес! – диештеләр. –
Төбәкләргә көрәшергә кайтып китик,
Ил байлыгы иминлеген тәэмин итик!"
Җил-давыл купкандай шунда көрәш купты.
Ул көрәшү соңгы байлыкларны йотты.
Беркем көрәшүчеләргә калмады эш.
Һәр көрәшүчегә эләкте бик мул өлеш.

# КОНДЫЗ – ТӨЗҮЧЕ

Төзергә кыланды Кондыз урман халкына
Бик шәп күпер. Бушка түгел, алтын хакына.

Әйтте Бүрегә (Казнага бүген ул хуҗа):
– Кул кулны юа, Бүре дус, күрмәбез нужа.

Чыгымнары төзелешнең булса биш йөз мең,
Килешү төзергә миллионга комачаулый кем?..

Сиңа чирек, миңа чирек – безнең өлешләр.
Эчне тишмәс өлешләргә төшкән көмешләр...

Төзелеш томам. Күпер дигәне тар басма шунда.
Киекләр үтеп чыгалмый күрше басуга.

Тикшерү килде. Аюхан урманда судья.
Әйтте судья:
– Әй син, Кондыз, намусың кайда?!

Күпер дә юк, миллион да юк, кайда куйдыгыз?
Бүре белән икәүләшеп урлар булдыгыз?...
Кондыз әйтте:

– Аю абзый, бар өеңә кайт.
Безнең эшләр бурлык түгел, бары тик откат.



Әнә Төлке – һичшиксез бур, тавык урлаган,
Ул тавык бит кеше милке дип тормаган.

Аны утырт, безгә тимә, без бит бур түгел.
Откат – зурлык! Угрылык та, бурлык та түгел.

Ул – заман казанышы дип, тыңлыйбыз кат-кат.
Безнең эшне туктатып куй. Мә сиңа откат.

Тартынгандай итеп Аю бер карап куйды,
Уфтанды... акчалы капчыны учына йомды.

Җәза әй-һәй йомшак булды - кисәтү бары.
Превышение полномочий – судның карары.



## ШӨШЛЕ *

Бер ширкәттә гомер бакый
Тегәр булганнар итек.
Җибәргәннәр бер көн монда
Шөшләсе хуҗа итеп.

Яңа хуҗа эш күрсәткән,
Бик зур яңалык кертеп,
Чабата үрләргә башлаган.
Ташлап тегүне итек.

* Шөшле – чабата үрү коралы.



## АЮ ТҮРӘ БУЛГАЧ

Баш урманга хуҗа булып алгач,
Аю «бөек» эшләр башкарды.
Кытайга да агач озатты ул,
Финнар иленә дә аткарды.

Бүреләрне сатты зоопаркка,
Шәшкеләрдән туннар тектерде.
Биләмәгә бай аучылар җыеп,
Пошиларны атып бетерде.

Киекләргә авыр көннәр килде,
Тал-чыбыкка калды урманы.
Череп баеп китте Аю түрә,
Аю түгел, буржуй торганы.

Һәр нәрсәнең була диләр чиге,
Бердән бер көн Аю тотылды.
Тотылды!..
Тик, мөлкәтем үземнеке түгел,
Бичәмнеке, диеп котылды.

Хәзер Аю тәкерәп тә бирми
Үзе талап киткән урманга.
Урман аның нәрсәсенә кирәк,
Яшәвеше Римда булганда.

...Бур түрәләр шпайдәләр илдә.
Урлыйлар да, чыгып качалар.
Лондоннарда, Парижларда, Римда
Кәеф-сафа корып яталар.
Безне жәлләп:
– Яши белмисез сез,
Мескеннәр! – дип хәбәр саталар.





*Ни әйтсәң дә, очу – яхшы,*
*Очу – күңелле шөгыль.*
*Тик Җиргә кайтачагыңны*
*Оныту яхшы түгел.*

# ТАМЧЫ ҺӘМ КАР БӨРТЕГЕ

Керләнгән карны телгәли
Язның ялбыр камчысы.
Күктә болыт, тәрәздә
Ялгыз бер Су тамчысы.

Менә-менә кояш чыгар,
Тамчы тулышып җитәр.
«Тып» итеп тамып төшәр дә,
Әллә кайларга китәр.

Тик таралмый һаман болыт,
Ачылып җитми күге.
Тамчы эргәсенә шул чак
Кунды бер Кар бөртеге.

Тамчы әйтте:
– Сылу! Мин шат!
Икәү бергә тамарбыз.
Шук гөрләвек кочагында
Еракларга агарбыз.

– Әй Тамчы, – ди Кар бөртеге. –
Төсең ни дә, ни буең.
Хыялың синең канатсыз,
Җиргә сеңү бар уең.

Мин бит синең тиңең түгел,
Син – мужик, мин – аксөяк.



Бу дөньяда миндәй чибәр,
Миндәй затлылар сирәк!

Ял итеп алам да бер тын,
Тагы күкләргә очам.
Соклансын миңа бар галәм.
Очам... йолдызлар кочам...

Шулчагында чыкты кояш.
Тамчы тупылдап тамды.
Кар бөртеге куйган төштә
Кечкенә бер тап калды.

Ни әйсәң дә, очу – яхшы,
Очу – күңелле шөгыль.
Тик Җиргә кайтачагыңны
Оныту яхшы түгел.



## ЮЛЛАР

Киндекләрне буйлап горур ята
Өр-яңа юл – такыр Автобан.
Машиналар җилә җырлый-җырлый:
– Олы рәхмәт Байга! Олы дан!

Янәшәдә генә Басу юлы
Үлән арасында шуыша.
Асфальтның данлы иясенә,
Янәсе дә, ана булыша.

Басу юлын санга сукмый Асфальт,
Үзен күрә түгел, һавалы.
Тешен кысып дәшә:
– Үзеңә кара,
Күтәрелеп миңа карале.

Аэродромдай киңмен, таудай биек,
Өстем пыяладай тап-такыр!
Үлән арасында, күренмичә,
Боргаланасың бит син бахыр...

Миндә җилә күпме иномарка,
Синдә йөри ялгыз трактор.
Синең белән туган булу гарьлек,
Читкәрәк кит. Миннән ерак тор.

...Баксаң, асфальт түшәп бетелмәгән,
Ярты юлда ташлап киткәннәр.



Техникасы әллә ватылганмы?
Акчасынмы урлап беткәннәр?

Менә үргә күтәрелгән иде,
Асфальт тауга килеп терәлде.
Басу юлы тауны урап үтте,
Елганы да җиңел кичелде.

Хакимнәре хәзер ана төште.
Машиналар – басу юлында.
Ничек кенә аны сукмасыннар,
Язмышлары аның кулында.

Кимсенүнең олысына түзгәч,
Кыенсынмый түзде бик әзгә.
Чыккан булса ничек авылыннан,
Басу юлы җитте мәркәзгә.



# КАБАН ДУҢГЫЗЫ

Берчак шулай урман киекләре
Җыелышып киңәш кордылар.
Тормышыбыз бигрәк күңелсез дип,
Бәйрәм үткәрергә булдылар.

«Исәнмесез, урмандашларыбыз!» –
Шулай атадылар чараны.
Читтән кунаклар кайтыр, диештеләр,
Якынайтып ерак араны.

Кайтмадылар, чөнки монда яши
Урманның бар улы һәм кызы.
Кунак булып, үзен зурга куеп,
Кайтты бары Кабан дуңгызы.

Ул да кайчан читтә күрмәс иде,
Яшь чагында алып киткәннәр.
Тоткын җанварларга иш иттереп,
Күчмә зоопаркта йөрткәннәр.

Олыгайгач чыгарганнар куып,
Шундый фәрман биргән зур түрә.
Мескен дуңгыз әле (монысы – сер)
Шәһәр чүплегендә көн күрә.

... Бәйрәм – бәйрәм инде. Киекләрне
Түрдә басып Аю котлады.



Котлады да... без, кешеләр, кебек,
Тост күтәреп хәмер йотмады.

Күңел ачу шулай кызып китте,
Бүре озын көен җырлады.
«Әпипә»гә басты шаян Куян,
Оялып-нитеп бер дә тормады.

Менә чират җитте кунакка. Ул
Тагарактан башын күтәрде,
Битәр хисс тулы караш белән
Бар табынны күздән үткәрде.

Башлады ул:
– Мин булмагач монда,
Рәте китеп бара урманның.
Бот күтәреп көтеп ятасызмы
Аның чүп-чар белән тулганын?..

Сирәгәйтмәгәнсез куакларны,
Асфальт җәймәгәнсез аланга.
Келәт төзеп һаман куймагансыз
Ипи чикләвеге сакларга.

Зоопаркта халык яхшы яши,
Ә сез һаман иңкә килмисез.
Теләсә нинди өндә көн күрәсез,
Читлек төзеп керә белмисез.

Бик күп җирдә йөрдем, бик күп гаҗәп
Нәрсә күреп кайттым мин анда.

Синең язуң фәкыйрь, мәгънәсез,
Мәдәният юк бит урманда...

Бәйрәм үтте. Ничектер моңсу бетте,
Булмаса да артык әллә ни.
Эшем шәседәй, китте Дуңгыз
Кайтып «мохитенә мәдәни».

...Кунак булып тыйнак булмаганнар
Арабызда әле җитәрлек.
Кайткан чакта, сатуларын акыл
Тыңлап торсаң, исең китәрлек.





# БАКА БЕЛӘН КҮБӘЛӘК

Күбәләк куды камышка,
Бака калыкты өскә.
Бака Күбәләккә дәште:
– Әй чибәрсең дә тәскә!

Көн-төн чәрелдәгән бичәм
Инде тәмам туйдырган.
Авызы зур. Әйтерсең дә,
Балта белән уйдырган.

Үзе юан, мичкә кебек,
Ике күзе акайган.
Бөтен тәнен сөял баскан,
Тотып үбәрсең кайдан?

Менә синә, Күбәләккәй,
Бер генә кочсам иде.
Хыялымны канат итеп,
Оҗмахка очсам иде.

Күбәләгә юмарт икән:
– Бик теләсәң, коч, – диде. –
Хет хыялыңда булса да
Оҗмахыңа оч, – диде.

Тик син, сазлык сандугачы,
Бер нәрсәне белеп куй.
Мине кочу бушка түгел,
Колагыңа элеп куй.

Мин бит валютный күбәләк,
Мин – алтынга бәрабәр,
Түлә ике йөз евро,
Бер кочам дисәң әгәр.

«Бак-ка-как?!.» – диде Бакабыз,
Ике күзе акайды,
Авызы ачылып китте,
Йотардай булып айны.



Төше булмастаен сизеп,
Күбәләк очып китте.
...Ни әйтик соң? Шуның белән
Әкиятебез бетте...





# МИНДЕК

Ягылган мунча. Ләгәндә
Миндек су кереп ята.
Тик ятмый, чөйгә элмәгән
Мунчалага гап сата:

– Бу дөньяда Хуҗабызның
Миннән дә якыны юк.
Моны инкар итүчеңең
Башында акылы юк.

Минем аркала Хуҗабыз
Татый пешүнең тәмен.
Мин генә сыйпарга хаклы
Аның кадерле тәнен.

Ул тәнне бит шап-шоп итеп
Мин генә чаба белөм,
Иң кычыткан төшләрен дә
Мин генә таба беләм.

Тышкы дөньяда Хуҗабыз
Бөек кеше, зур түрә.
Монда мин бит аңа сердәш,
Мине генә тиң күрә.

Мунчада, димәк, түрә – мин!
Ни әйтсәм дә, күнегез.

Миңа каршы сөйләсәгез,
Кыска булыр көнегез.

Мин әйтик, син, Мунчала,
Ни эшлисең мунчала?
Хуҗаны белмисең, парсый,
Белмисең аны чабу…

Мунчала дөньяда. Бәхәскә
Вакыт калмаган иде.
Кыйган мунчага Хуҗаның
Дуамал улы керде.

Сүтеп-сүтеп чабылды ул,
Ике кулы талганчы.
Мактанчык каен себерке
Тал-чыбыкка калганчы.

Кыска булды Миңлек гомере –
Язмышыдыр, күрәсең.
Чүпләккә аттылар чыгарып
Мунчаның «зур түрәсен».





## АРЫСЛАН НӘСЕЛЕ

Әллә уйнап, әллә чынлап
Мәчене кемдер масайткан.
Чыганак кайдан тапкандыр,
Ана шәҗәрә язаткан.

Баксаң, Мәченең нәселе
Батырлардан тора икән.
Селәүсен дә, Ягуар да
Аңа туган була икән.

Затлылыгы бу нәселнең
Барлап чыккан, чиктән ашкан.
Шәҗәрәнең тамыр очы
Арысланга ук тоташкан.

Болай да һавалы Мәчегә
Бу ишарә җитә калды.
Ул түшенә арыслан башы
Тошкан бизге тагып алды.

Масаюы чиктән ашты,
Хәзер Мәче тычкан тотмый.
– Мин – арыслан нәселе! – дип,
Кәч житкәнен тотып тукмый.

Мин – арыслан токымы! – дип,
Күкрәк сугып көн уздыра.

Балаларыне кыерсыта,
Чебешләрне пыр туздыра.

Берчак шулай, кызып китеп,
Уяулыгын ул югалтты.
Бер чебешне куып йөреп,
Әтәч тырнагына капты.

Әтәч чукыды Мәчене,
Арт ягына каты типте.
Йорттагы кош-корт алдында
Аны бик нык мыскыл итте.

– Арысланнан песи тумый –
Бел син моны, Мәче, – диде, –
Үзен арыслан санаган
Песи тәле әче, – диде.

Әтәч хәрәмы – тавыклар
Кыткылдашып көлештеләр:
– Моңлый хурлыкка калганнан
Үлем артык… – диештеләр.







# ҮРМӘКҮЧ, БАЛ КОРТЫ ҺӘМ ЧЕБЕН

Бал кортына килгән ди Үрмәкүч:
– Әйдә икәү дуслар булыйк, – дигән, –
Таган кордым, ефәк аркан асттым,
Атынышып бергә уйныйк, – дигән.

Бал корты Үрмәкүчкә әйткән ди:
– Котыртма, вакытым минем бик тар.
Шау чәчәккә күмелгән юкәлек,
Һәр чәчкәдә ташып тора нектар.

Бал кортының, чынлап та, эше тыгыз.
Эш өстендә көннәре үтә торган.
Һаман да керемен чамалап Үрмәкүч
Үтә дә мәкерле планын корган.

Бал кортына тагы дәшкән ди ул:
– Сәбәп тапма син минем качарга.
Хәзер, мөгаен, бардыр форсатың
Җан дустың белән күңел ачарга…

Бал кортының әзер ди җавабы:
– Котыртып юк эшкә йөрмә син болай.
Көннәр буе очам, эшем тыгыз.
Чәчкә аткан кырда караболай.

Андагач Үрмәкүч эше чыкмасын,
Килеп тапкан шапалак Чебенне.
Дәшкән аңар
– Син миңа ошыйсың,
Нигә белмим генә сыйлыйм үзеңне?

Чебен әйткән:
– Үрмәкүч абзыкай!
Минем болай да сыйлы тамагым.
Әнә почмакта батут корганысың,
Аны тирәләп очып карадым.

Ай-һай шәп чыккан! Рәхәт итсәң,
Сикерим анда күңелем булганчы.
Үрмәкүч бик шат:
– Сикер, Чебенкәй,
Төннәр узганчы, таңнар туганчы.

Сикергән дә Чебен эләккән тозакка.
Үрмәкүч килеп угын батырган,
Җилеген суыргач, корбанының
Алдатучы итеп кабыгын катырган.

Наркотик – заманның иң зур бәласы.
Алдыра күп яшьләрне бүгенге.
Шушы мәкерле аугa капканнар
Хәтерләтәләр акылсыз Чебенне.



## ЭКСТРАСЕНС КҮКЕ

Илебез – гади ил түгел,
Күрәзәчеләр иле.
Бихисап алар үрчеде
«Үзгәреш»ләребез бирле.

Шундыйларның берсе Күке.
Берсе, берсәйлесе.
Бөтен халык шәп дип мактый
Күкенең юрау көче.

Минем гомерем ничә ел дип,
Сорасалар Күкедән,
Җавапны ул бик тиз таба,
Кирәк чаклы күкеләп.

Шартлатып салый да бирә,
Кемгә – йөз, кемгә – илле.
Ышаналар: «Юравы, – дип, –
Ай-һай да дөрес килде!»

Әле Күкегә беркемнең
Дәгъва белдергәне юк.
Ничек белдерсен соң адәм,
Җиталмаса йөзгә үк.

Иллене үтеп киткән дә
Аны бигрәк алмый.

Оттым экстрасенсны дип,
Үзен-үзе ул алдый.

Булачак үзгәрешләрне дә
Шук Күке белеп тора.
Кызыксынган адәмнәргә
Мәгълүмат биреп тора.

Әйтик, егерме елдан соң
Кемнәр күпме алачак,
Хәстәрле илебез салымны
Кемгә күпме салачак.

Күкегә мөрәҗәгать күп,
Эше аның муеннан.
Хәтта ваз да кичте Күке
Бала табу уеннан.

Күрәзә итмәслекме соң!
Халык агылып тора.
Күке кесәсенә йөзләр,
Меңнәр тамызып тора.

Тамчыдан күлләр җыела.
Күке бай, эше җиңел!
Шулай булмый, ничек булсын,
Илебез – күкеләр иле...



# АЮ ҺӘМ БУРСЫК

Яшәешнең тайпылышсыз кануннары,
Бердән бер көн Аюга да Әҗәл килде:
– Фанилыкта сиңа дигән бетте ризык,
Бакыйлыкка күчәр көнең җитте, – диде.

Урман өчен зур югалту, авыр кайгы,
Ул бит йөрде исемлегендә бөекләр.
Соңгы юлга озатканда Аюханны
Үксеп-үксеп елаштылар бар киекләр.

Даһиларны озатканда соңгы юлга,
Озатырга даһиларның килүе фарыз.
Җирләшергә диеп якын дустын хәтта
Зоопарктан сорап чыкты карт Юлбарыс.

Матәм чарасы рәисе әрсез Төлке
Тәүге сүзне, билгеле инде, ала бирде.
– Бик вакытсыз китте мәрхүм... – диде дә ул,
Буылып күз яшьләренә, башын иде.

Баскан иде бар акланны авыр тынлык,
Көтмәгәндә һичкем, Бурсык сүз сорады.
– Мәрхүмнең иң якыны – мин идем, – дип,
Аптыратып бар акланны хәбәр салды. –

Яшәү, ашау рәвешебез охшаш булгач,
Барыгыздан да Аю мине өстен күрде.

Күчеләндәге сорауларга җавап эзләп,
Бүләкләргә эч серләрен миңа йөрде.

Зиратта бит ыгы-зыгыга юк урын.
Бу чыгышны дошман-иптәш тыңладылар.
«Дөнья кызык. Үләгәч бөекнең дуслары
Ишәя», – дип эчтән генә уйладылар.

Аю китте... Бурсык әле яши һаман.
«Дустым иде!» – дип һаман да хәбәр сата.
Хәтирәләр белән бик еш чыгыш ясый,
«Мин һәм Аю» дигән китап язып ята.





# СӘЯХӘТЧЕ ТЫЧКАН

Тычкан кайтты сәяхәттән, озак йөреп,
Океан-диңгезләрне кичеп, дөнья күреп.

Туган-тумачасы килгән, күрше-күлән...
Тычкан эре, борыны өскә күтәрелгән.

Килде Күсе, олы башын кече итеп,
Сорау бирде:
– Йә туганкай, йөздең ничек?

Тычкан сөйли:
– Йөздем океан лайнерында.
«Трюм» атлы каютада, җайлы урында.

Ашаганым булды, – ди, – чик ярма, ботка.
Кайгырмадым һич кенә дә иптәш юкка.

Чили дигән ерак илдә иптәш таптым.
Горурланам! Аның белән мин дуслаштым.

«Шиншилла» дип олылыйлар, безгә туган.
Бездәй кимерүче булып җиргә туган.

Затлы җәнлек! Аны байлар тиң күрәләр.
Үзен суеп, тиресен тунап, тун тегәләр.

Шиншилла тун тора икән миллион евро.
Аны тегеп кия алмый һичбер угры.

Олигарх бичәләре кебек кия,
Йә әйтегез, мондый хөрмәт кемгә тия?!.

Ә мине бит ана дустым тигез күрде,
Анд таулары итәгендә озатып йөрде.

Их! Шиншиллалай шулай затлы булсаң икән,
Аның кебек байлыкларга чумсаң икән!..

Күсе җилләнсен кашыды, әйтте бер сүз:
– Гади тычкан булсаң да, син, әнием, түз.

Шатлан тикмәгәнгә синең затлы толып,
Яшәү татлы, кешене дә тычкан булып.





## ЯФРАК

Җәй уртасы. Аерылып анасыннан,
Бер Яфрак өзелеп төште агачыннан.

Җиргә төшмәде Яфрак, суга төште,
Ашыгып тормышка хыялын чиле-пешле.

Бераз гына әйләнмәдә әйләнде ул,
Өскә карап, анасына бәйләнде ул.

– Котылып синнән, ниһаять, мин китәм, – ди,
Йөзә-йөзә океан-диңгезгә җитәм, – ди.

Монда калган яфракларың саргаерлар,
Җилләп мескеннәрне хәтта Карга елар.

Ә мин җылы океанда су керермен,
Мәңге яшел тропикта көн күрермен.

Яфрак китте... Чаган калды шәлен болгап,
Ил ташлаган яфракларның хәлен уйлап...

Елга ага, дулкыннарын кага-кага,
Дулкын каккан барлык чүп-чар ярда кала.

Ерак китмәде Яфрак, аз юл үтте,
Ләм катыш чүп-чар астында көне бетте.

## СӘГАТЬ

Стенада иске Сәгать
«Келт» тә «келт» йөреп тора.
Секундларны, минутларны
Һаман да белеп тора.

Аларны санавы бер эш,
Нәфесен зурга суза.
Мактана:
– Җирдә дәверләр
Мин йөрсәм генә уза.

Мине сакламасагыз, ди, –
Сезне зур афәт көтә.
Мин туктасам, Вакыт туктый,
Дөньяда яшәү бетә.

Берчак шулай карт Сәгатьнең
Җитте азаккы көне.
Капыл гына туктап калды,
Көрмәлеп тутык теле.

Металломга ватык Сәгать,
«Келт» тә «келт» инде йөрми.
Үлеп китте, гади генә
Хакыйкатьне төшенми.

Вакыт төймәсе басарга
Җитми һичкемнең кулы.
Вакыт буйсынмый Сәгатькә,
Сәгать вакытның колы.



## МӘЧЕ ҺӘМ ЮЛБАРЫСЛАР

Песи булып яшәү авыр.
Язмышыбыз дип әче.
Юлбарыслар нәселе
Кушаллы эрсез Мәче.

Кече туганына санап,
Өер аны үз итте.
Эше юк, телгә шәп Мәче
Борчакны әре чиртте.

– Халыкка хезмәт итүче
Миндәй Юлбарыс сирәк.
Телебезне, динебезне
Саклап калырга кирәк.

Без бөек халык булганбыз,
Бөек булып калабыз.
Юлбарыстай тусын Җиргә
Һәр тудырган балабыз.

Ышанды өер Мәченең
Өргән һәр кушыгына.
Аның илдәге иң бөек
Юлбарыс булуына.

Арымый-талмый гел сатты ул,
Түгеп тирләрен әче.
Тәмле ашап, тәмле йоклап,
Җан тәслим кылды Мәче.

Исемен саклыйк дип тарихта
Ала Һөнкәп куйдылар
«Бөек юл күрсәтүче» дип
Ташка язу уйдылар.

...Юлбарыс бөек, йөрәгендә
Горурлыгын саклаган.
Кемгә әйләнер, бер килмешәк
Сызган юлдан атласа?..





## БҮРЕЛӘР

Өч бүре идарә итте
Сарык көтүе белән.
Сарыкларның иминлеген
Саклады алар гелән.

Үз-ара тыныч яшәде,
Ызгышу юк, юк талаш
Соры бүре көн дә килә,
Аласы көн аралаш.

Агы килми, әмер бирә:
– Китерегез, – ди, – ашка!
Китерәләр иң симезен,
Ак бүре, диеп, патша.

Сарык бетте. Тик үлмәде
Ачтан угры бүреләр.
Төрле кыйтгаларда яши,
Алар һаман тереләр.

Соры бүре Һималайда,
Таулар илендә ямьле.
Тау кәҗәләренә ул баш,
Кәҗә ите дә тәмле!

Африкада Ала бүре,
Чүл бүресе ул хәзер.

Газельләр күп. Ятса-торса
Сыйланыр азык әзер.

Ак котыпта көн күрә,
Карлы-бозлы якларда,
Алда ялланган, ди, имеш,
Тюленьнәрне сакларга.

...Бүре – бүре булып кала,
Кайда гына йөрсә дә,
Бүре булып уласа да,
Шакал булып өрсә дә...,





## БОЛЫТ

Томра эссе. Аяз күктә
Хасил булды кара болыт.
Яңгыр көткән бар тереклек
Өметләнеп калды тынып.

Якынлашты, зурайды ул,
Алды каплап ярты күкне.
Вәгъдә итте дөбер-шатыр
Әллә азны, әллә күпне.

Купты давыл, туздЫ тузан,
Ялт-йолт итте яшен-камчы.
Китте болыт, калды тамып
Күз яшедәй өч-дүрт тамчы.

...Бәндәләр бар шул болыттай,
Бар гайрәте мин-минлектә.
Вәгъдә дә зур, дәгъва да зур,
Тик файда юк өч тиенлек тә.

# САНДУГАЧ БЕЛӘН КАРЛЫГАЧ

— Мин шәп очам! — ди Карлыгач.
— Мин моңлы, — ди Сандугач,
Тыңлый бар дөнья җырымны
Җәй көннәрен таң тугач.

Сандугач белән Карлыгач,
Кайсысы соң хаклырак?
Шәп очу яхшымы, әллә
Шәп җырлавымы яхшырак?

Бәхәскә куйды ноктаны,
Бер Тилгән очып килеп.
Карлыгач уктай атылды,
Явызның уен сизеп.

Бирелеп җырлый Сандугач
Очып китәлми калды.
Җырткыч кош мескен җырчыны
Умырып тотып алды.

Кушты аннары тоткынга
Дәвам итәргә җырын.
Әсәрләнми-нитми генә
Тыңлаган булды моңын.



Әйтте аңа: «Әй син, йолкыш,
Матур җырлыйсың икән.
Ашыйсым килсә дә бик нык,
Мин сине азат итәм».

Сандугач белән Карлыгач
Бәхәсләшүчеләр башка.
Сәбәп юк бәхәсләшергә,
Бер фикер ике башта.

...Бу дөньяда әсирләрне
Язмыш үткәрә иләк.
Иләкләрдән үтәр өчен
Һөнәрле булу кирәк.



# ҮРӘКОЙРЫК

Кәҗә улы Үрәкойрык,
Тыңламыйча анасын,
«Тек» тә «тек» сөзеп маташа
Абзарның баганасын.

Бу хәлне тамаша кыла
Абзардагы бар халык:
Алаша Ат, мүкләк Сыер,
Кунычадагы Тавык...

Шук бәтине очындырып
Инде гел мактыйлар:
– Абзар ишелеп төшмәсен,
Сөзсәң дә сөз сак! – диләр.

Үрәкойрык үсеп җитте.
Ул гәүдәсе, ул сыны!
Пар кылычтай мөгезләре,
Дебеттән җиңгән туны.

Акылга да зәгыйф түгел,
Түгел һич ул дивана.
Гаҗәбе шул: баганасын
Һаман сөзеп юана.

Хәзер аны мактамыйлар,
Хәзер аннан көләләр:



– Балалыгыннан чыгалмый,
Бигрәк юләр! – диләр.

...Кеше хайванга тиң түгел,
Әйтәсе килә өзеп.
Батырлар булып кыланмыйк,
Абзар терәүен сөзеп.



# ЙОМЫЧКА

Чиксез киңлекләр илендә дәрья булып елга ага.
Сөзәк ярга бөрелә-сугыла бер Йомычка йөзеп бара.

Әле ары, әле бире теплоходлар тора үтеп,
Гудоклары яңгырап кала, еракларга барып җитеп.

– Сәлам сезгә, иркен кырлар! Сәлам сезгә, тау, урманнар!
Сагынып безне көтеп алып, ихлас карашылап торганнар.

Көлсәң көл, инде көлмәсәң, аптыраудан егыл да кит!
Йомычкабыз һәр сәламне кабул итә үзенә дип.

– Сәлам, «Маяковский»! * – ди, – Саумы, «Василий Буслаев»!**
Минем генә йөзешемне, дустым «Салават Юлаев»?, ***–
Их «Есенин»! ****
Тотрыксыз син, боргаланасың агымда.

---

* Теплоход исемнәре



Иңем терәгәннәр булды, батып та барган чагында.

Хәтерлисең булыр, шулай без бер портта торган идек,
Бөтен шәһәрне шаулатып, мәҗлесләр корган идек...

...Көтмәгәндә купты давыл, күк йөзен каплады болыт.
Йомычка, сөйләнә-сөйләнә, ярга бөрелеп калды торып.

Бу хикәят – мәзәк кенә. Аңысын сез аңлыйсыздыр.
Бөекләр һәм йомычкалар – бәлки чамалыйсыздыр...

## ИДӘН БЕЛӘН ТҮШӘМ

Үзе тигез, үзе шома,
Үз эшендә, йөз шомс...
Масаеп түбәнгә карый
Ошы йортның Түшәме.

Аста – Идән, ул да тигез,
Ул да түгел кечкенә.
Авыр бурычын башкара,
Тик масаймый һич кенә.

Авыр булмый, инде булсын,
Көн-төн таптап йөриләр.
Бәйрәмнәр еш булып тора,
Идән басып бииләр.

Кем аралаш банкетлары,
Атна саен юбилей...
Көтмәгәндә
Түшәм Идәнгә сүз куйты:
– Мин – бөек, син – плебей.

Бигрәк авыр бит тормышың,
Кызганам сине һаман...
– Туктале, ди, – Идән анда, –
Кем акыллы, кем надан?

Бер нәрсәгә төшенмим мин:
Масаясың син нидән?



Аскы ягың түшәм булса,
Өске ягың бит идән...

...Идән – түшәм. Түшәм – идән.
Дөнья да шулай кат-кат.
Астан карап сокланалар,
Өстән йөриләр таптап.



# ТӨЛКЕ ХӘСРӘТЕ

Аю киткәч пенсиягә,
Калды Бүре түрә булып.
Аю эшен дәвам итә
Аягында нык(лы) торып.

Элекке хуҗаны киекләр,
Белдермичә сагынуларын.
Исләреннән чыгармыйлар
Янда шымчы Төлке барын.

Аю белән бик дус иде,
Хәзер ул дус Бүре белән.
Анда барып, монда килеп,
Агу чәчә теле белән.

– Озак еллар хуҗа булып,
Аю бер эш кырмады, – ди. –
Менә ичмасам Бүребез
Түрәләрнең уңганы! – ди.

Җилләр төрле яктан исә,
Дөньялар үзгәрә һаман.
Ихтирам итәргә Аюны
Өстән төшкән, имеш, фәрман.

Ә Төлкегә нишләргә соң?
Ничек соң хурга калмаска?



Аюны сүккәне өчен
Ничек бәлага тарымаска?

– Аю булмады начар, – ди, –
Булса да ул чалыш табан.
Башкарган эшләре белән
Һич Бүредән калышмаган...

...Менә шундый танышым бар,
Юньсез түгел тәү карашка.
Тик җил кайсы яктан исә,
Башын бора шул тарафка.



## ЭНӘ БЕЛӘН ҖЕП

Энә әйтә: "Мин тегәм", – ди.
Җеп мактана: "Мин тегәм.
Мин тектән киемнәр матур.
Җөйләре тигез, төгәл!"

Энә тагы күкрәк суга:
"Мин югары, син түбән.
Миңа тагылып йөрисең син,
Бар көчемне мин түгәм..."

Җеп бирешергә теләми:
"Мәсхәрә! Ни ишетәм?!.
Башка бер генә күлмәк тә
Текмим, сиңа үч итәм"

Энә: "Сүзләрең, – ди, – эче,
Ятышсызлар колакка.
Ачуга бик тисәң, әйләндем
Куйдым энә Уймакка".

Яшь бу пар менә шулай.
Инде гомерләр узган.
Хәзер алар берни текми,
Энә – тутык, Җеп – тузган...



## ТӨТЕН, БОЛЫТ ҺӘМ КОЯШ

Күтәрелде Төтен һавага,
Хыялына ул да иреште.
Болыт эргәсендә урын алды.
Шул Болытка карап сүз дәште:

– Охшаш диләр безнең икебезне,
Тик мин зәңгәр, ә син карасың.
Мин биеккә күтәреләм һаман,
Ә син түбән төшеп барасың.

Биек яшим дип мактандың син,
Менә мин дә хәзер биектә.
Син гомердә биек булалмадың,
Ә мин булалырмын биек тә...

Болыт дәшми түбәнрәк төште,
Яңгыр булып җирне сугарды.
Соңгы чиккә җитеп сусыраган
Бар табигать җиңел тын алды.

Кояш чыкты, көлеп аңа дәште.
Таралып та барган Төтенгә.
– Син нәрсә, – дип, – Төтен, барасыңмы
Акылыңнан язып бөтенләй?

Белергә бит хәзер вакыт инде:
Син – бер мескен сөрем тузаны.

Болыт – тереклекне яңартучы,
Яшәтүче яңгыр томаны.

Гарьлегеннән Кояш сүзләреннән
Күп тә үтми Тотен таралды.
Гайрәтләнеп үз өрелгән төштә
Эз калмады, сасы ис калды...







# ВЕРТОЛЕТ ҺӘМ ЭНӘ КАРАГЫ

Һаваларны байкый бер Вертолет,
Саз өстендә – Энә карагы.
Очып килеп кунды үз камышка,
Баш күтәреп күккә карады.

Тирә-ягын аннан барлап алды,
Бөҗәкләргә карап сүз дәште:
– Ничегрәк очып йөри анда,
Күрәсезме минем кардәшне!

Мин – өйрәттем аны җирдән күккә
Кузгалырга, тузан борхытып.
Болытларны кисеп, юл ярырга,
Койрыгын шулай тез тотып.

Тик әлегә күп нәрсәне белми,
Белми камышларга кунарга.
Өйрәтергә кирәк әле аны
Осталыкка энә урларга.

Белми ничегрәк җим табарга
Күл читендә, сары сазларда.
Качып котылырга чуртаннардан,
Комсыз үрдәк, сөмсез казлардан...

Осталыгын бергә шомарталсак,
Биргән бәһам анда «биш» булыр.

Бу саллыкта миңа җиткәннәр юк,
Бәлки, ул, дим, миңа иш булыр.

...Биеклэрдә оча бөекләр,
Ихтирамга лаек эшләре.
Аларның да кайчак табылып тора
Эш карагалдай «эш»ләре.







# КИГӘВЕН

Бу илдә бар сәер гадәт.
Шул гадәтне саклыйлар.
Ат тир түгә, тик нигәдер
Кигәвенне мактыйлар.

Имеш, атка туры юлны
Тик Кигәвен күрсәтә.
Бертуктаусыз бимазалап,
Атны тик ул эшләтә.

Әгәр Кигәвен булмаса,
Чирәм сөрелмәс иде.
Көзен буразларга тулып
Иген игелмәс иде.

Атның канын ул эчмәсә,
Чабылмас иде печән...
Кыскасы, Кигәвен булдыклы,
Кигәвен гел эшчән.

...Хәзер басуда трактор,
Ул заман инде үткән.
Картайган Ат хаклы ялда,
Кигәвен мәрхүм күптән.

Тик аны һич онытмыйлар
Барлык чебен-черкиләр.

– Рухы – безнең истә, – диләр, –
Рухы – безгә көч! – диләр.

Басуга исем биргәннәр,
Ул – Кигәвен басуы.
Юл чатында кукраеп
Тора Кигәвен сыны.

Чабышлар илендә гадәт,
Шул гадәтне саклыйлар.
Ат эшләгән, тик һаман да
Кигәвенне мактыйлар...





## ТӘНКЫЙТЬЧЕ ЭТ

Капка астыннан энчек Эт
Киң дөньяга күз ата.
Күз ату белән чикләнми,
Ләңгелдәп өреп ята.

Киң дөнья – бу энчек өчен
Тротуарның бер ягы.
Үткән-сүткән адәмнәрнең
Тездән түбән аягы.

Шул аякларга өрә ул,
Шул аяклардан көлә.
Тәнкыйть утында яндыра,
Үзенчә бәһа бирә.

– Бу аяклар кәкре, – ди, –
Болары баса кыеш.
Төз басарга минем алар
Үрнәк алырга тиеш.

Менә бу адәм аягын
Атлый сөйрәтеп җиргә.
Атламый, әйтерсең, төшкән
«Ламбада»ны биергә.

Бу аяклар тукмалдыйлар
Кәҗә тоягы сыман...

Кыскасы, күңелле бик юк.
Урам түгел бу урам...

...Адәмнәр бар, тәнкыйтьлиләр
Олысын, кечесен дә,
Дөньяда булган хәлләрнең
Ачысын, төчесен дә...

Тик зәгыйфь бик фикерләре,
Аз тормыш белүләре.
Бәһаләре, тәнкыйтьләре –
Әнчек эт өрүләре.

## ЭЧТӘЛЕГЕ


Кереш сүз. Уйнап та, уйлап та... 3
Галәмәт тормыш 8
Каргалар 11
Саескан – депутат 12
Йолак 15
Кәҗә белән Сарык 16
Чикерткә белән Кырмыска 18
Балык 19
Аю һәм бүреләр 21
Өч эт 24
Ишәк 26
Гадел Бүре 28
Бөркет һәм Чыпчык 30
Тукран түбәсе 32
Чуртан белән Ташбаш 33
Аю – фил докторы 35
Бака язмышы 38
Көрәшү 39
Кондыз – төзүче 40
Шүрәле 42
Аю түре булгач 43
Тычкан һәм Кар бөртеге 46
Юллар 48
Кабан дуңгызы 50
Бака белән Күбәләк 53
Миндек 55
Арыслан нәселе 57
Үрмәкүч, Бал корты һәм Чебен 59
Экстрасенс Күке 61
Аю һәм Бурсык 63





Сихерче Тычкан 65
Яфрак 67
Сәгать 68
Мәче һәм юлбарыслар 69
Бүреләр 71
Болыт 73
Сандугач белән Карлыгач 74
Урманйорты 76
Йомычка 78
Иден белән Түшәм 80
Төлке хөрмәте 82
Энә белән Җеп 84
Төтен, Болыт һәм Кояш 85
Вертолет һәм Энә карагы 87
Кигәвен 89
Тәнкыйтьче эт 91
Эчтәлек 93

*Литературно-художественное издание*

Акберов Закир Насырович
(Закир Әкбәров)

*УДИВИТЕЛЬНАЯ ЖИЗНЬ*

*Басни*

*(на татарском языке)*

Редактор Айгуль Шакметова
Набор Закир Акберов
Верстка и оформление Заля Насырова
Корректор Расима Хапиева